РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Микулинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 74, Азнакаевский район,
с.Микулино, 423306,
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
башкарма комитеты

Советская ур., 74 йорт, Азнакай районы,
Микулино авылы, 423306
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «31»01.2023г.** **№1**

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 гыйнварендагы 119 номерлы карары нигезендә «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2023 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 7 793,48 сум (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә.
2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2022 елга «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында» 2022 елның 28 гыйнварендагы 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

http://pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык И.А.Такиулин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл жирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта

"31"01.2023 №1

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3693,48 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1500,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2600,00 |
| 4 | **Барлыгы** | **7793,48** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл жирлеге башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта

"31"01.2023 №1

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1400,00 |
| 2 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2293,48 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1500,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2600,00 |
| **5** | **Барлыгы** | **7793,48** |